Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Кичү авыл Советы

# КАРАРЫ

23 апрель2024 ел №87

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районыКичү авыл җирлеге Советының 2021 елның29октябрендәге 23номерлы «Кичүавыл җирлегендә муниципаль хезмәт хакындагы нигезләмәне раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында «Федераль законның 12 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 12 декабрендәге 594-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында" 2024 елның 01 мартындагы 11-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына нигезендә, Әлмәт шәһәр прокуратурасының 2024 елның 16 мартындагы 08-02-08/163 номерлы күрсәтмәсен карап

Кичүавыл Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районыКичү авыл җирлеге Советының 2021 елның29 октябрендәге 23 номерлы «Кичүавыл җирлегендә муниципаль хезмәт хакындагы нигезләмәне раслау турында»гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районыКичү авыл Советның 2023 елның20 февралендәге 59 номерлы, 2023 елның 01 августындагы 72 номерлы, 2023 елның 14 декабрендәге 81 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1.карарга кушымтада:

1.1.1. 5 бүлекнең «Муниципаль хезмәткәрнең хокукый хәле»5.5 пункты13 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13) яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) Нигезләмәнең 24.2 бүлегендә каралган анкетадагы белешмәләрнең үзенә мәгълүм булган үзгәрешләр турында язма рәвештә хәбәр итәргә, моңа яллаучы (эш бирүче) вәкиленең карары буенча үзгәргән белешмәләр керми (алга таба - анкетадагы белешмәләр).»;

1.1.2.6 бүлекнең «Муниципаль хезмәт белән бәйле чикләүләр» турында 6.1 пункты 8 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8)муниципаль хезмәткә кергәндә һәм (яисә) аны узу чорында ялган документлар һәм муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә тоткарлык ясый торган чикләүләрнең, тыюларның һәм таләпләрнең үтәлешен раслый торганялган документлар һәм белешмәләрне тапшыру, яки муниципаль хезмәт

вазыйфасын биләүне тоткарлый торган чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәүне раслый торган документларны һәм белешмәләрне тапшырмау;»;

1.1.3. 9 бүлекнең «Муниципаль хезмәткә керү, аны узу һәм туктату тәртибе» 9.3 пункты 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) әлеге Нигезләмәнең 24.2. булегендә каралган анкета»;

1.1.4. 9 бүлекнең «Муниципаль хезмәткә керү, аны узу һәм туктату тәртибе»9.4 пункты«мәгълүмат» сүзеннән соң «(анкетада булган мәгълүматлардан тыш)»сүзләре белән тулыландырырга;

1.1.5.11 бүлекнең «Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс» 11.9 пунктыб пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) әлеге Нигезләмәнең 24.2 булегендә каралган үз кулы белән тутырылган һәм имзалангананкета;»;

1.1.6. 11 бүлекнең «Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә Конкурс» 11.19 пунктында «өч» сүзен «ике»гә алмаштырырга;

1.1.7. 18 бүлекнең «Кадрлар эше» 18.1 пункты 11.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм аны үткән вакытта граждан тарафыннан бирелә торган мәгълүматларны тикшерүне оештыру һәм үткәрү;»;

1.1.8. 18 бүлекнең «Кадрлар эше» 18.1 пункты11.1 пунктчасын түбәндәге эчтәлектәге белән тулыландырырга:

«11.1) дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматларга билгеләнгән форманы кертүне рәсмиләштерү.»;

1.1.9. 18 бүлекнең «Кадрлар эше» 18.2 пунктынын 10 пунктчасы беренче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10.Максатлы укыту турында килешүтөзү конкурсындаРоссия Федерациясенең дәүләт телен белгән, тиешле дәрәҗәдәге һөнәри белем алучы һәм укуны тәмамлаганнан соң хезмәт мөнәсәбәтләре барлыкка килүгә китерә торган укучы яки башка килешү буенча йөкләмәләре булмаган гражданнар катнаша ала.»;

«11.1) билгеләнгән рәвешкә дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләргә рөхсәт кәгазе рәсмиләштерү.»;

1.1.10. 18 бүлекнең «Кадрлар эше» 18.2 пункты 11 пунктчасының 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

2) әлеге Нигезләмәнең 24.2 бүлегендә муниципаль хезмәткә керә торган граждан тарафыннан җирле үзидарә органына тапшыру өчен каралган үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкета, фотография кушымтасы белән;»;

1.1.11. 24 бүлекнең «Керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүмат бирү»24.8., 24.8.1., 24.8.2. пунктларын төшереп калдырырга;

1.1.12. нигезләмәне түбәндәге эчтәлектәге 24.1, 24.2. бүлекләр белән тулыландырырга:

**«24.1. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә мәгълүмат урнаштыру турында мәгълүмат бирү**

24.1.1. «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендәге сайтлар һәм (яки) сайт битләре адреслары турында мәгълүмат, анда муниципаль хезмәт вазыйфасына дәгъва итүче граждан, муниципаль хезмәткәр һәркемгә ачык мәгълүмат урнаштырган, шулай ук аларны яллаучы вәкиленә идентификацияләргә мөмкинлек бирүче мәгълүматлар,:

1) хезмәткә кергәндә муниципаль хезмәт вазыйфасына дәгъва кылучы граждан,муниципаль хезмәткә керү елына кадәрге өч календарь елда;

24.1.2. 24.1.1 пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән мәгълүматлар., муниципаль хезмәткә кергәндә муниципаль хезмәт вазыйфасына дәгъва итүче гражданнар тарафыннан, ә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан хисап елыннан соң 1 апрельдән дә соңга калмыйча тәкъдим ителә. 24.1.1 пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән мәгълүматлар., Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән форма буенча тәкъдим ителә.

24.1.3. Эш бирүче вәкиле карары буенча, ул вәкаләтле муниципаль хезмәткәрләр «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль хезмәт вазыйфасына дәгъва итүчеләр һәм муниципаль хезмәткәрләр урнаштырган һәркемгә ачык мәгълүматны эшкәртәләр, шулай ук 24.1.1 пунктында каралган мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерәләр.

**24.2. Анкетаны тәкъдим итү, анкетада булган мәгълүматны үзгәртү турында хәбәр итү һәм мондый мәгълүматны тикшерү**

24.2.1. Муниципаль хезмәткә кергәндә граждан анкета тәкъдим итә.

24.2.2. Муниципаль хезмәткәр яллаучы (эш бирученең) вәкиленә анкетада булган мәгълүматларның аңа билгеле булган үзгәрешләр турында язма рәвештә хәбәр итә.

24.2.3. Анкета формасы, шул исәптән анда кертелгән мәгълүматлар исемлеге, аларны актуальләштерү тәртибе һәм вакыты Россия Федерациясе Президенты тарафыннан билгеләнә.

24.2.4. Анкетада булган мәгълүматлар яллаучы (эш бирүче) вәкиле яки аның вәкаләтлесе карары буенча тикшерелергә мөмкин. Анкетада булган мәгълүматларны тикшерү муниципаль органның кадрлар хезмәте тарафыннан тиешле мәгълүматка ия булган иҗтимагый хакимият органнарына һәм оешмаларга язма рәвештә, шул исәптән дәүләт мәгълүмат системалары аша, запрослар җибәрү юлы белән башкарыла. Тиешле мәгълүматка ия булган җәмәгать хакимияте органнары һәм оешмалары соралган мәгълүматны әлеге сорауны алганнан соң бер айдан да соңга калмыйча бирергә тиеш.».

2. Әлеге карарны Әлмәт районы,Кичү авылы, Үзәк урам, 50 нче йорт; Нагорное авылы, Үзәк урам, 17йортадресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында игълан итәргә, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Кичүавыл җирлеге башлыгы Г.П.Туманова

КИЧУЙСКИЙ СЕЛЬСКИЙ СОВЕТ